Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

5 ноябрь, 2025 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Татар Казысы авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Татар Казысы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 129 номерлы Татар Казысы авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 14 декабрендәге 33 номерлы карар белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Татар Казысы авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

Гражданнар җыенын ике этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2025 елның 27 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Мәктәп, Яңа, Кооператив, Яшьләр урамнары йортлары буенча исемлектә теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабын 2025 елның 27 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Үзәк урамы, 6 йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет, Комсомол, Ерак урамнары йортлары буенча исемлектә теркәлгән кешеләрне кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026 елда Татар Казысы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татар Казысы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Татар Казысы авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Кәримуллин